# СОГЛАШЕНИЕ
## между Республикой Татарстан и Приморским краем о торгово-экономическом, научно-техническом и социально-культурном сотрудничестве

Республика Татарстан в лице Президента Республики Татарстан Минниханова Рустама Нургалиевича, действующего на основании Конституции Республики Татарстан, с одной стороны и Приморский край в лице Губернатора Приморского края Кожемяко Олега Николаевича, действующего на основании Устава Приморского края, с другой стороны, именуемые в дальнейшем «Стороны»,

руководствуясь законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и законодательством Приморского края (далее – законодательство),

в целях развития межрегиональных связей на основе принципа взаимной выгоды,

признавая, что расширение взаимовыгодного сотрудничества отвечает интересам населения Республики Татарстан и Приморского края и способствует экономическому развитию Республики Татарстан и Приморского края,

выражая взаимную заинтересованность в развитии двусторонних связей на стабильной и долгосрочной основе и желая создать для этого соответствующие организационные, экономические, правовые и иные необходимые условия, заключили настоящее Соглашение о нижеследующем.

### Статья 1

Настоящее Соглашение направлено на установление сотрудничества между Сторонами в торгово-экономической, научно-технической и социально-культурной сферах и определяет направления сотрудничества Сторон в указанных сферах.

### Статья 2

Стороны воздерживаются от действий, которые могли бы нанести экономический или иной ущерб друг другу, обмениваются информацией о решениях, принятие которых может затронуть права и законные интересы Сторон.

### Статья 3

В области торгово-экономического, промышленного, инвестиционного и инновационного сотрудничества Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

разрабатывают совместные проекты, направленные на развитие экономического и инновационного потенциала Республики Татарстан и

Приморского края, проводят обмен делегациями специалистов по отраслям, представляющим взаимный интерес;

содействуют созданию условий для установления и расширения деловых контактов между хозяйствующими субъектами, зарегистрированными и осуществляющими хозяйственную деятельность на территориях Республики Татарстан и Приморского края (далее – хозяйствующие субъекты), разработке и реализации программ по развитию и поддержке предпринимательства в Республике Татарстан и Приморском крае;

взаимодействуют в сфере инвестиционной и инновационной деятельности, в том числе разрабатывают и реализуют меры по стимулированию инвестиционной активности с целью повышения конкурентоспособности и обеспечения роста экономики Республики Татарстан и Приморского края;

организуют бизнес-миссии и презентации инвестиционных площадок и инвестиционного потенциала, информируют друг друга о проведении на территориях Республики Татарстан и Приморского края инвестиционных форумов, конференций и иных мероприятий инвестиционной направленности;

развивают систему информационно-аналитического обеспечения, определяя наиболее эффективные формы реализации инвестиционных проектов;

развивают механизмы государственно-частного партнерства;

обмениваются информацией и лучшими практиками реализации проектов и программ в сфере развития инвестиционной деятельности;

совместно прорабатывают вопрос целесообразности создания оптово-распределительных центров на территории Республики Татарстан экспортно ориентированными предприятиями Приморского края;

способствуют развитию транспортного сообщения между Республикой Татарстан и Приморским краем;

содействуют созданию Регионального маркетингового центра Приморского края и использованию электронных площадок etp.zakazrf.ru, 223etp.zakazrf.ru, sale.zakazrf.ru, биржевой площадки bp.zakazrf.ru для государственных и муниципальных нужд, а также для нужд юридических лиц, закупки которых регулируются Федеральным законом от 18 июля 2011 года № 223-ФЗ «О закупках товаров, работ, услуг отдельными видами юридических лиц»;

обмениваются опытом в области реализации в Республике Татарстан и Приморском крае требований стандарта развития конкуренции в субъектах Российской Федерации, утвержденного распоряжением Правительства Российской Федерации от 17 апреля 2019 года № 768-р.

## Статья 4

В области сельского хозяйства Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции оказывают содействие организациям агропромышленного комплекса в сфере товарооборота путем создания необходимых организационных условий по следующим направлениям:

растениеводство, селекция, семеноводство, взаимное использование передовых технологий, растительного генофонда, экологически чистых методов

и средств защиты растений при возделывании зерновых и прочих сельскохозяйственных культур;

животноводство, разведение, содержание и кормление высокопродуктивных сельскохозяйственных животных на базе современных технологий, осуществление технического обновления механизированных ферм;

биотехнология, биотехнологическое управление производством сельскохозяйственных культур и размножением животных, перерабатывающая, пищевая промышленность, комплексное использование средств механизации и автоматизации производственного процесса.

**Статья 5**

В области здравоохранения и биофармацевтики Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

обмениваются опытом в части организации системы здравоохранения, оказания медицинской помощи населению Республики Татарстан и Приморского края;

содействуют обмену делегациями специалистов медицинских организаций Республики Татарстан и Приморского края;

взаимодействуют в сфере создания и развития биофармацевтических кластеров.

**Статья 6**

В области социальной защиты и занятости населения Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

развивают сотрудничество по вопросам обеспечения занятости населения, социальной поддержки и социального обслуживания населения, в том числе разработки и реализации правовых актов в указанной области, осуществляют взаимодействие и обмен опытом работы по реализации программ социально-экономического развития, социальных программ поддержки семьи, материнства, детства, граждан пожилого возраста и инвалидов;

обмениваются делегациями специалистов органов управления социальной защиты населения и службы занятости населения и учреждений социального обслуживания населения для изучения опыта работы в части внедрения новых социальных технологий;

обмениваются информационно-аналитическими материалами о состоянии безработицы и положении на рынке труда.

**Статья 7**

В области охраны окружающей среды и обеспечения экологической безопасности, государственного ветеринарного надзора и устойчивого существования животного мира Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

обмениваются информацией о проводимых в Республике Татарстан и Приморском крае мероприятиях по охране окружающей среды и обеспечению экологической безопасности;

обмениваются опытом по вопросам обращения с отходами производства и потребления, внедрения новых технологий сортировки, переработки и утилизации отходов, совершенствования управления природоохранными структурами;

сотрудничают в области организации, охраны и использования особо охраняемых природных территорий, ведения Красных книг, охраны и использования объектов животного мира;

обмениваются информацией и опытом работы по вопросам реализации мероприятий в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов;

обмениваются информацией об обустройстве и содержанию мест утилизации биологических отходов;

обмениваются опытом работы в области охраны окружающей среды и рационального природопользования, а также улучшения состояния окружающей среды;

обеспечивают распространение и внедрение передового опыта работы в области охраны окружающей среды в хозяйствующих субъектах;

совершенствуют систему непрерывного экологического образования и воспитания населения, развивают экологическую культуру;

организуют совместные природоохранные мероприятия, проводят совместные рабочие встречи, тематические семинары, заседания круглых столов и другие мероприятия по проблемам, представляющим взаимный интерес.

## Статья 8

В области культуры Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

обмениваются информацией о предстоящих культурных событиях и мероприятиях, проводимых в Республике Татарстан и Приморском крае, в том числе имеющих международный характер, с целью возможного участия в них коллективов и исполнителей из Республики Татарстан и Приморского края;

оказывают содействие укреплению и развитию культурных связей;

взаимодействуют в организации и проведении гастролей творческих коллективов, обмениваются музейными, художественными выставками.

## Статья 9

В области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

организуют и проводят совместные семинары с привлечением научного сообщества, в том числе в онлайн-формате;

обмениваются опытом в сфере учета, сохранения и изучения объектов культурного наследия, государственного контроля и надзора, в том числе в онлайн-формате.

## Статья 10

В области государственного регулирования цен (тарифов, надбавок, наценок и др.) на товары (работы, услуги) Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

сотрудничают и обмениваются опытом, в том числе по вопросам осуществления контроля (надзора) за соблюдением требований законодательства в области регулируемых государством цен (тарифов);

сотрудничают и обмениваются опытом работы по организации взаимодействия органа регулирования тарифов с органами местного самоуправления по вопросам утверждения и мониторинга соблюдения предельных (максимальных) индексов изменения вносимой гражданами платы за коммунальные услуги.

## Статья 11

В области архивного дела Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

обмениваются опытом и информацией о нормативных и методических разработках, информационных технологиях;

принимают участие в организации и проведении научно-практических конференций, семинаров, совещаний, выставок архивных документов, в подготовке публикаций по документам Архивного фонда Российской Федерации;

оказывают содействие друг другу в обеспечении доступа к архивным документам и научно-справочным материалам, необходимым для исследований и удовлетворения социально-правовых запросов граждан.

## Статья 12

В области образования и науки Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

проводят совместные конференции;

реализуют совместные научно-исследовательские проекты;

осуществляют взаимодействие и обмен опытом по вопросам сохранения и развития этнокультурного образования;

обмениваются опытом по разработке современных образовательных технологий, проектов правовых актов в сфере образования.

## Статья 13

В области информатизации и связи Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

развивают взаимовыгодное сотрудничество в области информационных технологий посредством реализации инвестиционных проектов;

обмениваются делегациями преподавателей, исследователей и других специалистов;

стимулируют развитие наукоемких отраслей путем создания совместных предприятий или технологического сотрудничества и обучения.

## Статья 14

В области спорта и молодежной политики Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

способствуют участию спортсменов и спортивных сборных команд Республики Татарстан и Приморского края в спортивных и спортивно-массовых мероприятиях, проводимых на территориях Республики Татарстан и Приморского края;

содействуют участию молодежи в межрегиональных молодежных мероприятиях, реализуемых в Республике Татарстан и Приморском крае.

## Статья 15

В области туризма Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

обмениваются информацией о предстоящих мероприятиях на территориях Республики Татарстан и Приморского края;

содействуют установлению взаимных контактов между туристскими организациями, осуществляющими деятельность на территориях Республики Татарстан и Приморского края.

## Статья 16

В области строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

обмениваются опытом в области организации строительства, градостроительной политики и в сфере жилищно-коммунального хозяйства;

обмениваются делегациями органов государственной власти, осуществляющих полномочия в области строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства;

участвуют в международных, республиканских и краевых выставках, семинарах и конференциях строительной, градостроительной и архитектурной тематики, проводимых на территориях Республики Татарстан и Приморского края.

### Статья 17

В целях повышения эффективности и результативности деятельности органов местного самоуправления Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции содействуют развитию межмуниципального сотрудничества и обмену опытом в сфере организации и осуществления местного самоуправления.

### Статья 18

В сфере реализации государственной национальной политики Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

содействуют сближению и взаимообогащению культур народов, проживающих на территориях Республики Татарстан и Приморского края;

создают необходимые условия для удовлетворения национально-культурных интересов народов, проживающих на территориях Республики Татарстан и Приморского края;

участвуют в разработке и реализации совместных проектов по взаимодействию с национально-культурными объединениями;

при организации визитов рассматривают предложения о включении в составы делегаций руководителей национально-культурных объединений.

### Статья 19

Настоящее Соглашение не затрагивает обязательств Сторон по заключенным ими соглашениям (договорам) с третьими сторонами, не препятствует их выполнению. Стороны обмениваются информацией, необходимой для реализации настоящего Соглашения, заблаговременно информируют друг друга об изменениях в законодательстве Республики Татарстан и законодательстве Приморского края, которые могут повлиять на выполнение настоящего Соглашения.

Настоящее Соглашение не налагает на подписавшие его Стороны финансовых и (или) имущественных обязательств.

Положения настоящего Соглашения не могут рассматриваться как создающие благоприятствующие условия для деятельности отдельных хозяйствующих субъектов, которые могут иметь своим результатом ограничение конкуренции или ущемление интересов иных хозяйствующих субъектов.

Настоящее Соглашение является основой для заключения Сторонами соглашений и протоколов (планов мероприятий) в конкретных сферах сотрудничества.

### Статья 20

В случае возникновения споров между Сторонами по вопросам реализации настоящего Соглашения Стороны разрешают их путем переговоров.

**Статья 21**

Настоящее Соглашение вступает в силу со дня его подписания Сторонами и заключается сроком на пять лет, по истечении которого автоматически продлевается на последующие пятилетние периоды до тех пор, пока одна из Сторон не менее чем за три месяца до истечения очередного пятилетнего периода письменно не уведомит другую Сторону о своем намерении прекратить действие настоящего Соглашения.

С момента подписания настоящего Соглашения Соглашение между Республикой Татарстан и Приморским краем о торгово-экономическом, научно-техническом и культурном сотрудничестве от 26 ноября 2011 года признается утратившим силу.

Действие настоящего Соглашения может быть досрочно прекращено по соглашению Сторон.

Настоящее Соглашение может быть изменено по соглашению Сторон. Все изменения к настоящему Соглашению оформляются в письменном виде и являются его неотъемлемой частью.

Совершено «1» июля 2021 года в г. Арсеньеве в двух экземплярах, имеющих одинаковую силу, каждый на русском и татарском языках, по одному экземпляру для каждой из Сторон.

В случае возникновения разночтений для целей толкования настоящего Соглашения Стороны руководствуются текстом на русском языке.

| За Республику Татарстан | За Приморский край |
|---|---|
| Президент Республики Татарстан | Губернатор Приморского края |
| Р.Н. Минниханов | О.Н. Кожемяко |

05.07.2021
№ 34

**Татарстан Республикасы һәм Приморье крае арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында**
**КИЛЕШҮ**

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы йөзендә Татарстан Республикасы бер яктан һәм Приморье крае Уставы нигезендә эш итүче Приморье крае Губернаторы Кожемяко Олег Николаевич йөзендә Приморье крае икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Приморье крае законнарына һәм (алга таба – законнар) таянып,

үзара файда принциплары нигезләрендә төбәкара багланышларны үстерү максатларында,

үзара файдалы хезмәттәшлекне киңәйтүнең Татарстан Республикасы һәм Приморье крае халкы мәнфәгатьләренә туры килүен һәм Татарстан Республикасының һәм Приморье краеның икътисадый үсешенә булышлык итүен танып,

ике яклы элемтәләрне тотрыклы һәм озак вакытлы нигездә үстерүгә үзара кызыксыну күрсәтеп һәм моның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар булдырырга теләп, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

**1 статья**

Бу Килешү сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә Яклар арасында хезмәттәшлек урнаштыруга юнәлтелгән һәм әлеге өлкәләрдә Якларның хезмәттәшлеге юнәлешләрен билгели.

**2 статья**

Яклар бер-берсенә икътисадый яисә башка зыян китерерлек гамәлләрдән тыела, аларны кабул итү Якларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылырга мөмкин булган күздә тотылган карарларны килештерә һәм алар турында мәгълүмат алмаша.

**3 статья**

Яклар сәүдә-икътисадый, сәнәгать, инвестиция һәм инновация хезмәттәшлеге өлкәсендә законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

Татарстан Республикасының һәм Приморье краеның икътисадый һәм инновация мөмкинлекләрен үстерүгә юнәлтелгән уртак проектлар эшли, үзара кызыксыну тудырган тармакларда белгечләр делегацияләре белән алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территорияләрендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары (алга таба –

хуҗалык субъектлары) арасында эшлекле багланышлар булдыру һәм аларны киңәйтү өчен шартлар булдыруга, Татарстан Республикасында һәм Приморье краенда эшкуарлыкны үстерүгә һәм аңа булышлык күрсәтү программалары эшләүгә һәм аларны гамәлгә ашыруга ярдәм итә;

инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән Татарстан Республикасының һәм Приморье краеның икътисадын үстерүне тәэмин итү һәм конкурентлык сәләтен арттыру максатларында инвестицион активлыкны стимуллаштыру чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра;

бизнес-миссияләр, инвестиция мәйданчыклары һәм инвестиция мөмкинлекләрен тәкъдим итүне оештыра, Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территорияләрендә инвестиция форумнары, конференцияләр һәм инновация эшчәнлегенең башка чаралары уздыру турында бер-берсенә хәбәр итә;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның аеруча нәтиҗәле рәвешләрен билгеләп, мәгълүмати-аналитик тәэминат системасын үстерә;

дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын үстерә;

инвестиция эшчәнлеген үстерү өлкәсендәге проектлар һәм программаларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат һәм иң яхшы тәҗрибәләр алмаша;

Татарстан Республикасы территориясендә Приморье краеның экспортка эшләүче предприятиеләре тарафыннан кумәртәләп сату-булү үзәкләрен төзүнең максатка яраклыгы мәсьәләләрен бергәләп тикшерә;

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае арасында транспорт элемтәсен үстерүгә ярдәм итә;

Приморье краеның төбәк маркетинг үзәген төзүгә һәм etp.zakazrf.ru, 223etp.zakazrf.ru, sale.zakazrf.ru электрон мәйданчыкларын, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен, шулай ук сатып алу эшләре «Аерым юридик затлар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына торган юридик затлар өчен bp.zakazrf.ru биржа мәйданчыгын файдалануга булышлык күрсәтә;

Татарстан Республикасында һәм Приморье краенда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында конкурентлыкны үстерү стандартлары таләпләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә тәҗрибә алмаша.

## 4 статья

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә агросәнәгать комплексы оешмаларына тиешле оештыру шартлары тудыру юлы белән түбәндәге юнәлешләр буенча товар алмашу өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруда булышлык итә:

үсемлекчелек, селекция, орлыкчылык, бөртеклеләр һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын эшкәрткәндә, алдынгы технологияләрдән,

үсемлекләр генофондыннан, үсемлекләрне саклауның экологик яктан чиста ысулларыннан һәм чараларыннан бергәләп файдалану;

терлекчелек, заманча технологияләргә нигезләнеп продукция бирүчәнлеге югары дәрәҗәдә булган авыл хуҗалыгы терлеген үрчетү, асрау һәм ашату, механикалаштырылган фермаларны техник яктан яңартуны тормышка ашыру;

биотехнология, авыл хуҗалыгы культуралары җитештерүгә һәм терлекләр үрчетүгә биотехнологик идарә, эшкәртү һәм азык-төлек сәнәгате, җитештерү процессында механикалаштыру һәм автоматлаштыру чараларын комплекслы куллану.

**5 статья**

Сәламәтлек саклау һәм биофармацевтика өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

сәламәтлек саклау системасын оештыруда, Татарстан Республикасы һәм Приморье крае халкына медицина ярдәме күрсәтүдә тәҗрибә алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае медицина оешмалары белгечләре делегацияләре белән алмашуга булышлык күрсәтә;

биофармацевтика кластерларын булдыру һәм үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек итә.

**6 статья**

Халыкны социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

халыкны эш белән тәэмин итү, халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча, шул исәптән әлеге өлкәдә норматив хокукый документлар кабул итү һәм аларны гамәлгә ашыру буенча да, хезмәттәшлекне үстерә, социаль-икътисадый үсеш программаларын, гаиләгә, аналарга, балаларга, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга ярдәм күрсәтү социаль программаларын гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлекне һәм тәҗрибә уртаклашуны тормышка ашыра;

яңа социаль технологияләр кертү өлкәсендә тәҗрибәне өйрәнү өчен халыкны социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү органнары һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре белгечләре делегацияләрен алмаша;

эшсезлек һәм хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат-аналитика материаллары алмаша.

**7 статья**

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү, дәүләт ветеринария күзәтчелеге һәм хайваннар дөньясының тотрыклы үсеше өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында һәм Приморье краенда уздырылган чаралар турында мәгълүмат алмаша;

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, калдыкларны сортларга бүлү, эшкәртү һәм аларны утильләштерүдә яңа технологияләрне гамәлгә кертү, табигатьне саклау структураларына идарәне камилләштерү мәсьәләләре буенча тәҗрибә алмаша;

аерым сакланучы табигать территорияләрен оештыру, саклау һәм файдалану, Кызыл китапларны алып бару, хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә хезмәттәшлек итә;

аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм эш тәҗрибәсе алмаша;

биологик калдыкларны утильләштерү урыннарын төзекләндерү һәм аларны карап тоту турында мәгълүмат алмаша;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану, шулай ук тирә-як мохитнең торышын яхшырту буенча эш тәҗрибәсе алмаша;

хуҗалык субъектларында әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә алдынгы эш тәҗрибәсен тарату һәм куллануга кертүне тәэмин итә;

халыкка экология өлкәсендә өзлексез белем һәм тәрбия бирү системасын камилләштерә, экологик культураны үстерә;

табигатьне саклау буенча уртак чаралар оештыра, үзара кызыксыну тудырган проблемалар буенча бергәләп эшлекле очрашулар, тематик семинарлар, түгәрәк өстәлләр һәм башка чаралар оештыра.

**8 статья**

Мәдәният өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

аларда Татарстан Республикасы һәм Приморье крае коллективлары һәм башкаручылары катнашу мөмкинлеген булдыру максатларында Татарстан Республикасында һәм Приморье краенда уздырылачак, шул исәптән халыкара дәрәҗәдәге мәдәни вакыйгалар һәм чаралар турында мәгълүмат алмаша;

мәдәни бәйләнешларны ныгытуга һәм үстерүгә булышлык итә;

иҗат коллективлары гастрольләрен оештыру һәм уздыру буенча хезмәттәшлек итә, музей, сынлы сәнгать күргәзмәләрен алмаша.

**9 статья**

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

фәнни җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, шул исәптән онлайн форматта да, уртак семинарлар оештыра һәм уздыра;

мәдәни мирас объектларын исәпкә алу, саклау һәм өйрәнү, дәүләт контроле һәм күзәтчелеге өлкәсендә, шул исәптән онлайн форматта да, тәҗрибә алмаша.

**10 статья**

Товарларга (эш һәм хезмәт күрсәтүгә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, бәя күтәрүне h.б.) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша, шул исәптән дәүләт тарафыннан бәяләрне (тарифларны) җайга салу өлкәсендә закон таләпләрен үтәүгә контрольлек итү (күзәтчелек) мәсьәләләре буенча да;

гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә түләү күләме үзгәрүенең чик (максималь) индексларын билгеләү һәм аларның үтәлешен мониторинглау мәсьәләләре буенча тарифларны җайга салу органының җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлеген оештыру буенча хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша.

**11 статья**

Архив эше өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

норматив һәм методик эшләнмәләр, мәгълүмат технологияләре турында мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша;

фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, архив документлары күргәзмәләре оештыруда һәм уздыруда, Россия Федерациясе Архив фонды документлары буенча мәкаләләр әзерләүдә катнаша;

тикшеренүләр алып бару, гражданнарның социаль-хокукый мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен кирәкле архив документларыннан һәм фәнни-белешмә материаллардан файдалану мөмкинлеген булдыруга бер-берсенә булышлык итә.

**12 статья**

Мәгариф һәм фән өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

бергәләп конференцияләр уздыра;

уртак фәнни-тикшеренү проектларын тормышка ашыра;

этномәдәни белем бирүне саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша;

заманча мәгариф технологияләре, мәгариф өлкәсендә хокукый актлар проектларын эшләү буенча тәҗрибә алмаша.

## 13 статья

Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыру рәвешендә мәгълүмат технологияләре өлкәсендә үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерә;

укытучылар, тикшеренүчеләр һәм башка белгечләр делегацияләре алмаша;

уртак предприятиеләр төзү яисә технологик хезмәттәшлек һәм укыту юлы белән фәнгә нигезләнгән тармакларны үстерүгә булышлык итә.

## 14 статья

Спорт һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае спортчылары һәм җыелма спорт командаларының Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территориясендә уздырыла торган спорт һәм массакүләм спорт чараларында катнашуына булышлык итә;

яшьләрнең Татарстан Республикасында һәм Приморье краенда гамәлгә ашырыла торган яшьләр өчен халыкара чараларда катнашуына булышлык күрсәтә.

## 15 статья

Туристлык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территорияләрендә уздырылачак туристлык чаралары турында мәгълүмат алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территорияләрендә эшчәнлек алып баручы туристлык оешмалары арасында үзара элемтәләр урнаштыруга булышлык итә.

## 16 статья

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

төзелешне оештыру, шәһәр төзелеше сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә тәҗрибә алмаша;

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә эшчәнлек алып барырга вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары делегацияләре алмаша;

төзелеш, шәһәр төзелеше һәм архитектура темасына Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территорияләрендә уздырыла торган халыкара, республика һәм край күргәзмәләрендә, семинарларда һәм конференцияләрдә катнаша.

## 17 статья

Яклар җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә муниципальара хезмәттәшлекне үстерүгә һәм җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә тәҗрибә алмашуга ярдәм итә.

## 18 статья

Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территорияләрендә яшәүче халыкларның үзара якынаюына һәм бер-берсенең мәдәниятләрен баетуына ярдәм итә;

Татарстан Республикасы һәм Приморье крае территорияләрендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыра;

милли-мәдәни берләшмәләр белән хезмәттәшлек буенча уртак проектлар эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

визитлар оештырганда делегацияләр составына милли-мәдәни берләшмәләр җитәкчеләрен кертү турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерә.

## 19 статья

Әлеге Килешү Якларның өченче яклар белән төзелгән килешүләре (шартнамәләре) буенча йөкләмәләренә кагылмый һәм аларны үтәү өчен киртә була алмый. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат алмаша, Татарстан Республикасы һәм Приморье крае законнарындагы әлеге Килешүне үтәүгә йогынты ясардай үзгәрешләр турында бер-берсенә алдан ук хәбәр бирә.

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм (яки) мөлкәт йөкләмәләре салмый.

Әлеге Килешүнең нигезләмәләре аерым хуҗалык субъектлары эшчәнлеге өчен башка хуҗалык субъектларының конкурентлыкка сәләтен чикләүгә һәм мәнфәгатьләрен кысуга китерәчәк уңай шартлар булдыру буларак карала алмый.

Әлеге Килешү Яклар тарафыннан хезмәттәшлекнең тәгаен өлкәләрендә килешүләр һәм беркетмәләр (чаралар планнары) төзү өчен нигез булып тора.

## 20 статья

Яклар арасында әлеге Килешүне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр туган очракта, Яклар аларны сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл итә.

**21 статья**

Әлеге Килешү аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм биш елга төзелә, шул вакыт узганнан соң, Якларның берсе үзенең әлеге Килешүне өзәргә теләве хакында алдагы бишьеллык чор тәмамланганчы кимендә өч ай кала икенче Якка язма рәвештә белдергәнгә кадәр, аннан алдагы бишьеллык чорларга үзеннән-үзе озайтыла.

Әлеге Килешүгә кул куелган вакыттан Татарстан Республикасы һәм Приморье крае арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында 2011 елның 26 ноябрендә төзелгән килешү үз көчен югалткан дип таныла.

Яклар үзара килешеп әлеге Килешүнең гамәлен вакыты чыкканчы туктата ала.

Яклар үзара килешеп әлеге Килешүне үзгәртә ала. Әлеге Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр язма рәвештә рәсмиләштерелә һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора.

2021 елның «1» июлендә Арсеньев шәһәрендә һәркайсы рус һәм татар телләрендә бер үк төрле көчкә ия ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды.

Килешмәүчелек очраклары килеп чыкса, Әлеге Килешүне шәрехләү максатларында рус телендәге текстка таянып эш ителә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы өчен | Приморье крае өчен |
| Татарстан Республикасы<br>Президенты | Приморье крае<br>Губернаторы |
| Р.Н. Миңнеханов | О.Н. Кожемяко |

05.07.2021
№ 34